# ЧИБӘР КЫЗ ГӨЛҮСӘ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Асыл ташлар арасыннан
Яратам фирүзәне.
Матур кызлар арасыннан
Яратам Гөлүсәне.

Диңгездә җилләр исә,
Бакчада гөлләр үсә.
Кем бәхетенә үскән икән
Чибәр кыз Гөлүсә?

2. Алмагачтан алма төшеп,
Җирләрне уяр микән?
Гөлүсәне кабат күреп
Күзләрем туяр микән?

Алма төшәр микән,
Җирне уяр микән?
Гөлүсәне кабат күреп
Күзем туяр микән?

3. Бакчадагы гөлләремнең
Тамырлары бер генә.
Кайчан да бер күрешербез –
Белмим көннәрен генә!

Ай, көннәрен генә,
Вай, көннәрен генә!
Күрешербез – белмим, бәгърем,
Тик көннәрен генә!

4. Һавадагы йолдызларны
Нигәдер санамадым.
Күз тияр дип йөзләреңә
Нигәдер карамадым.

Йолдыз санамадым,
Бәхет сынамадым,
Күз тияр дип йөзләреңә
Никтер карамадым.

5. Су буена бармас идем,
Су салкынын сизмәсәм.
Өзелеп җырлар язмас идем,
Гөлүсәне сөймәсәм.

Өзелеп сөймәсәм,
Сөюдән көймәсәм,
Синең өчен җан бирергә
Әзерлек сизмәсәм.

6. Җыр язам мин сиңа,
Ник язмыйсың миңа?
Җыр язам мин сиңа,
Ник язмыйсың миңа?

Син бит былбыл кебек миңа,
Мин ничек соң сиңа?
Син былбыл күк миңа,
Мин ничек соң сиңа?

7. Аклы ситсы күлмәгеңне
Өстәлләрдә кистеңме?
Йөзең гөлләргә охшаган,
Гөл эчендә үстеңме?

Күрсәт, бәгърем, үзеңне,
Нур сипкән йөзләреңне!
Көндәй ямьле, балдай тәмле
Зәңгәр күзләреңне!

8. Асыл ташлар арасыннан
Яратам фирүзәне.
Матур кызлар арасыннан
Яратам Гөлүсәне.

Диңгездә җилләр исә,
Бакчада гөлләр үсә.
Ак бәхетләр телим сиңа,
Чибәр кыз Гөлүсә!

**Красавица Гулюса**

Песня посвящается девушкам по имени Гулюса.

*Средь камней и гор великих*
*Всех красивей бирюза.*
*Средь девчонок белоликих*
*Всех красивей Гулюса.*

*Если в море ветер свищет,*
*То лишь тишь – в земных краях.*
*Красотою с детства блещет*
*Гулюса – любовь моя.*

*Все цветы в моем саду*
*Вскормлены одной рекой.*
*Где, когда, в каком краю –*
*Свидимся ли мы с тобой?*